



# ***Гараева Маһинур Каюм кызы***

*Мин, Гәрәева Маһинур Каюм кызы, 1931нче елның 3 нче апрелендә туганмын. Әти, өлкән яшьтә булуына карамастан, сугышка китте. Мәскәү тирәсендә сугышып, сугыш беткәннән соң 2 ел үткәч кенә исән-сау килеш әйләнеп кайтты. Аңа бик куандык инде. Сугыш башланганда миңа 10 яшь иде. Ашарга булмады. Күкәрин, кузгалак ашадык, ләкин аның белән генә тамак туймый иде.*

*Хезмәт стажым 45 ел. Авылда кибетче булып эшләдем. Шуннан соң бригадир булдым, аннары читкә китеп урман кистем. "Хезмәт ветераны" таныклыгы алдым, күп мактау кәгазьләре бирделәр. Хәзерге яшь буыннар  без күргәнне күрмәсеннәр, тазалык, саулык бирсен ходай, әйбәт кенә хезмәт итсеннәр, яшьләрнең тормышлары әйбәт булсын.*

